ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» октябрь 2020 ел № 331

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 апрелендәге 194 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәм аны хокукый анализ һәм законнардагы үзгәрешләрне мониторинглау нәтиҗәләренә туры китерү максатларында, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында " 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 апрелендәге 194 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, вазыйфаи оклад күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм Әгерҗе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын 11 498,00 сум күләмендә билгеләргә.»

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетында каралган чаралар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И.И. Шәмсетдинов**